КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 16 апрель г.Казань № 291

«Өстәмә һөнәри белем бирү буенча белем бирү программаларын гамәлгә ашыру» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип тану турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән «Өстәмә һөнәри белем бирү буенча белем бирү программаларын гамәлгә ашыру» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын расларга.

2. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өстәмә һөнәр белеме бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2011 ел, 18 август, 685 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өстәмә һөнәр белеме бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2011 ел, 18 август, 685 нче карары белән расланган Өстәмә һөнәр белеме бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 ел, 30 октябрь, 819 нчы карары.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин